ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция
Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ ҺӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТЕ ЙӨРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт
алкоголь инспекциясе)

# БОЕРЫК

26.07.2018 № 12-07/130

Казан ш.

Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең 23.05.2016 ел, № 12–07/38 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы дәүләти граждfestanлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарның үтәлешенә контрольлекне көчәйтү максатыннан чыгып, Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 19 сентября 2017 ел, № 431 Россия Федерациясе Президенты Указы һәм “Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында”

11 декабрь, 2017 ел, № УП-1092 Татарстан Республикасы Президенты Указы басылып чыгуга бәйле рәвештә, б о е р ы к б и р ә м:

1. “Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында” 23.05.2016 ел, № 12-07/38 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

түбәндәге эчтәлектәге 16.6 пунктны өстәргә:

“16.6. Бу Нигеләмәнең 16.1, 16.3 һәм 16.4 пунктларында күздә тотылган нигезле бәяләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) бу Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә һәм уведомлениеләрдә бәян ителгән мәгълүматларны;

б) запрослар нигезендә, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынулы оешмалардан алынган мәгълүматларны;

в) бу Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм уведомлениеләрне башлангыч төстә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгакны, шулай ук бу Нигезләмәнең 23, 24.3, 25.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карарны кабул итү өчен рекомендацияләрне.”.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка бу боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштырырга.

**4.** Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й.Әхмәтханов**